ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

Постановление                                   Карар

2019 елның 26 нчы сентябре      Чистай шәһәре      № 510

Чистай муниципаль районы
Башкарма комитетының
2019 елның 3 июнендәге
“Архив эше өлкәсендә дәүләт һәм
муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентларын раслау турында”гы
302 нче номерлы Карарына үзгәрешләр
кертү турында

«Россия Федерациясендә Архив эше турында» 2004 елның 22 октябрендәге 125-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының “Архив эше өлкәсендә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында”гы 2019 елның 3 июнендәге 302 номерлы карары белән расланган архив эшендә юридик затларга методик һәм практик ярдәм күрсәтү һәм эш башкаруда документлар оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертергә, 1.5 пунктының җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“архив документларын тәртипкә салу - архив документларын саклау (эш) берәмлекләренә формалаштыру, архив эше һәм эш башкару өлкәсендә федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән кагыйдәләр нигезендә, мондый саклау (эшләр) берәмлекләрен тасвирлау һәм рәсмиләштерү буенча эшләр комплексы;”.

2. Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының “Архив эше өлкәсендә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында”гы 2019 елның 3 июнендәге 302 номерлы карары белән расланган ликвидацияләнгән оешмаларның шәхси составы буенча документларны муниципаль архивка кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертергә, 1.5 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“архив документларын тәртипкә салу - архив документларын саклау (эш) берәмлекләренә формалаштыру, архив эше һәм эш башкару өлкәсендә федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән кагыйдәләр нигезендә, мондый саклау (эшләр) берәмлекләрен тасвирлау һәм рәсмиләштерү буенча эшләр комплексы;”.

3. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының архив бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында

( http://chistopol.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Башкарма комитет җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов